ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

25 май 2018 ел | Казан ш. | № 163

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 332нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль электр бүлү челтәрләренә технологик тоташу өчен түләүне һәм (яисә) мондый түләүнең зурлыгын (стандартлаштырылган түләү ставкаларын) билгеләү өчен куелган тариф ставкаларын куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының (алга таба - Дәүләт комитеты) норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатынннан боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 9 ноябрендәге 332нче боерыгы белән расланган (Дәүләт комитетының 2016 елның 29 июнендәге 164нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан территориаль электр бүлү челтәрләренә технологик тоташу өчен түләүне һәм (яисә) мондый түләүнең зурлыгын (стандартлаштырылган түләү ставкаларын) билгеләү өчен куелган тариф ставкларын куллануга бәйле бәхәсләрне карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктында:

1.3.1. пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.3.1. Дәүләт комитетының урнашкан урыны: Казан ш., К.Маркс ур., 66 йорт.

Дәүләт комитетының эш графигы: дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00дән 18.00гә кадәр; җомга 9.00дән 16.45кә кадәр; төшке ашка тәнәфес 13.00дән 13.45кә кадәр; шимбә - якшәмбе - ял көннәре.

Гаризаларны кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, һәр көнне, Дәүләт комитетының эш сәгатьләрендә.

Түбәндә аталган җәмәгать транспортларында «Толстой урамы» тукталышына кадәр барырга:

автобуслар: №№ 10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 54, 63, 83, 89, 91, 98;

троллейбуслар: №№ 2, 3, 5, 7, 8.

Кергәндә шәхесне таныклаучы документны күрсәтергә.»;

1.3.4.пунктчасындагы 5 абзацта «(http://uslugi.tatar.ru/)» сүзләрен «(http://uslugi.tatarstan.ru/)» сүзләренә алыштырырга;

1.4 пунктын яңа редакциядә бирергә:

«1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләргә ярашлы башкарыла:

«Электроэнергетика турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба - 35-ЗФ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, №13, 1177 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601нче Указына (алга таба - 601нче Указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, №19, 2338 б.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861нче боерыгы (алга таба - 861нче боерык) белән расланган Электр энергиясен кулланучыларның электр кабул итү җайланмаларының, электр энергиясен җитештерү объектларының, һәм шулай ук челтәр оешмаларына һәм башка затларга караган электр челтәре хуҗалыгы объектларының электр челтәрләренә технологик тоташуы кагыйдәләренә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2004, №52, 5525 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 9 гыйнварындагы 14нче карары (алга таба - 14 нче карар) белән расланган Технологик кушылу өчен түләү зурлыгын (стандартлаштырылган тариф ставкаларын) билгеләү өчен бәяләрне (тарифларны) көйләү буенча дәүләт органнары тарафыннан куелган мондый кушылу өчен түләү һәм (яисә) тариф ставкаларын билгеләүгә һәм куллануга бәйле бәхәсләрне көйләү кагыйдәләренә (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, №3, 414 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15

июнендәге 468нче карарына (алга таба - 468нче карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, №29, 1195, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880нче карарына (алга таба - ТР МКның 880нче карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, №46, 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2 бүлекнең 2 графасы:

2.5 пунктында «иясенә тапшыру турында хәбәр теркәлгән почта элемтәсе аша заказлы хат» сүзләрен «почта элемтәсе аша хат» сүзләренә алыштырырга;

2.13 пунктын түбәндәге эчтәлекле икенче абзац белән тулыландырырга:

«Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килгән гарызнамә (запрос) ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә теркәлә»;

5 бүлектә:

5.1 пунктында:

«шикаять белдерү» сүзләреннән соң, «карарлар һәм» сүзләре белән тулыландырырга;

5) пунктчада, «Россия Федерациясе» сүзләренннән соң, «законнар һәм башкалар белән» сүзләре белән тулыландырырга;

7) пунктчада, «кертелгән» сүзе алдыннан «алар тарафыннан» сүзләре белән тулыландырырга;

түбәндәге эчтәлектәге 8) - 9) пунктчалары белән тулыландырырга;

«8) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогын һәм тәртибен бозу;

«9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату, әгәр туктату өчен нигез булырлык сәбәпләр федераль законнарда һәм аларга ярашлы кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралмаган булса.»;

5.2. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Шикаять язма формада кәгазьдә, электрон формада Дәүләт комитетына юллана.»;

5.5 пунктын түбәндәге  редакциядә бирергә:

«5.5. Дәүләт комитетына килгән шикаять теркәлгәннән соң унбиш эш көне эчендә каралырга тиеш, Дәүләт комитетының гариза тапшыручының

документларын кабул итүдән яисә хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына карата шикаять белдерелгән очракта яисә мондый төзәтүләр өчен каралган срокларны бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - теркәлгән көннән биш эш көне эчендә.»;

5.7. пунктын юкка чыгарырга;

5.8.. пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.8. Шикаятьне тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) Шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документтагы хата һәм ялгышларны төзәтү формасында;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарту.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма формада һәм, аның теләге булса, электрон формада шикаятьне тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилле җавап юллана.»;

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары А.Л.Штромга йөкләргә.

Рәис М.Р.Зарипов